**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная, д.3,
г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

2024 елның «04» июле 10 номер

КАРАР

**Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир кишәрлеге территориясен ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, әйләнә-тирә мохитне саклап калу, территорияләрне планлаштыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өчен шартлар тудыру, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктына, 30, 31, 32 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып , Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир кишәрлеге территориясен ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә;

2. Кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар уздыру чорын - гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән алып нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр дип билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан ким һәм өч айдан артык була алмый;

3. Эш комиссиясенә Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан 16:24:170109:55 кадастр номерлы җир кишәрлеге территориясен манлау проекты буенча гавами тыңлауларны оештыруда һәм уздыруда әзерлек үткәрергә.

1.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган иҗтимагый фикер алышуларның башлануы турында хәбәр әзерләргә;

1.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне дәвамында әлеге карарның 3.1 пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы билгеләгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

1.3. Әлеге Карарның 2 п. күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

1.4. Гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне ахыргы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрергә..

4. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **В.А. Арефьев**